**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**2021елның 6 сентябре** **65-РСномер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Сокуры авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә 2018 елның 1 октябрендәге 56-РС номерлы үзгәрешләр кертү проектын раслау турында.**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы, 2021елның 11 августындагы гавами тыңлаулар беркетмәсе, 2021елның 12 августындагы гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ**:**

1. Лаеш муниципаль районының Сокуры авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә 2018 елның 1 октябрендәге 56-РС номерлы үзгәрешләр кертү проектын, кушымта нигезендә, расларга.
2. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.
4. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп тору Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.П. Шитовка йөкләнә.

**Башлык - муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**

"Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлегендә
җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү турында»Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Советы Сессиясенең 2021 елның
__ сентябрендәге ___ номерлы карарына кушымта

«**Шәхси торак төзелеше**», «**шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен**», «**блоклы төзелеш өчен**» рөхсәт ителгән җир кишәрлекләренең **минималь** күләмен **1000 кв. м.** дип билгеләргә.

«**Шәхси торак төзелеше**», «**шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен**», «**блоклы төзелеш өчен**» рөхсәт ителгән җир участокларының **максималь** күләмен **2500 кв. м.** дип билгеләргә.